Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

КАРАР КАРАР

19.12.2022 ел Менделеевск ш. №166

Педагогик хезмәткәрләр өчен җир кишәрлекләрен резервлау турында

Татарстан Республикасы Җир кодексының 21 статьясындагы 1.1 пунктчасы нигезендә, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставына таянып һәм югары квалификацияле педагогик кадрларны районның мәгариф учреждениеләренә җәлеп итү максатларында

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына Менделеевск шәһәре территориясендә шәхси торак төзелеше яисә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен 10 җир кишәрлеген район мәгариф учреждениеләренең югары квалификацияле педагогик кадрларына бирү максатларында резервларга.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетына Менделеевск муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы белән берлектә бер ай эчендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советына резервланган җир кишәрлекләрен педагогик кадрларга бирүне регламентлаучы норматив-хокукый актлар эшләргә һәм аларны карауга тапшырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының законлылыкны, хокук тәртибен һәм кеше хокукларын үтәү буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет рәисе Р.И.Беляев